Татарстан Республикасы
Азнакай районы
Сарлы авылы
урта гомуми белем бирү мәктәбе

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Шәйхетдинова Фәния Фәрәгать кызы

# Ибраһим Газиның тормыш һәм иҗат юлы.

# Максат:

VI сыйныфта укучылар-ны Ибраһим Газиның тор-мышы һәм иҗаты белән кыскача таныштыру.

# Ибраһим Зарифулла улы Мингазов



Татар әдәбиятының күренекле вәкиле, проза остасы, тәр-җемәче , публицист, тәнкыйтьче һәм ак-тив җәмәгать эшлек-лесе

# 1907-1971

1907 ел 4 февраль – Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Иске (Олы) Карамалы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.

1919-1924 еллар -Тәтештәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда урта белем ала.

1927 ел - әдәби иҗат эше башлана.

# Оста, иҗади тәрҗемәче

Сугышка кадәр үк А. Чехов, М.Горький, М.Салтыков-Щедрин, Мопассан, Э.Золя кебек классик язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итә.

1943 елдан башлап җиңү көннәренә кадәр - хәрәкәттәге армия сафында, фронтта татар телендә чыга торган "Сталин байрагы", "Кызыл армия" газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә, күп санлы очеркларын, кыска хикәяләрен ("Малай белән эт", "Әхмәт бабай", "Авылдаш" һ.б.) һәм "Алар өчәү иде" (1944) повестен яза.

Ибраһим Газиның эпик жанрдагы иң зур әсәре - "Онытылмас еллар" трилогиясе. Әлеге хезмәте өчен Ибраһим Газига 1969 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы һәм ике тапкыр "Почет билгесе " орденнары белән бүләкләнде.

1971 елның 21 февралендә йөрәк авыруыннан вафат булды.

“Һәр хикәям нинди дә булса бер вакыйга нигезендә туган. Алар һәммәсе дә үз заманының кыйпылчыгы. Барысына да заманнның кайнар сулышы сеңеп калган. Һәркайсының тарихы бар... Кайвакыт , хикәя тусын өчен, әһәмиятле бер буяуның табылуы да җитә. Калганын язучының хыялы үзе эшләп җиткерә.”

Ибраһим Гази.